РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 07 2019 г. №462

“2019-2020 елларның җылыту чорына
әзерлекне тикшерү уздыру” муниципаль
программасы турында

Ютазы муниципаль районы территориясендә Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы «Җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» гы 103 санлы боерыгын тормышка ашыру максатларында, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. “2019-2020 елларның җылыту чорына әзерлекне тикшерү уздыру" муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

А.Н. Захаров

2-81-49

Кушымта

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты карары белән расланды

№ _____ “____” ________- 2019 ел

**“2019-2020 еллардагы җылыту чорына әзерлекне тикшерү уздыру” муниципаль программасы**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1. Гомуми нигезләмәләр.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларының ышанычлылыгын тәэмин итү, җылыту чорына үз вакытында һәм һәрьяклы әзерләнү һәм тотрыклы җылылык, су, электр белән тәэмин итү максатында, аны оешкан төстә уздыру, энергоносительләрнең кирәкле параметрларын саклап калу һәм биналарда норматив температура режимын аларның билгеләнешен исәпкә алып тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының, торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының мөһим бурычы булып тора.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылыту чорына әзерләү температура һәм башка һава факторларының аларның эше ышанычлылыгына йогынтысын булдырмау, нормадан тыш тузуны һәм сафтан чыгуны кисәтү, шулай ук халыкның тормыш итү шартларын һәм коммуналь инфраструктура системасының эшләү режимнарын һәм биналарны җылыту чорында инженер-техник тәэмин итүне булдыру максатларында үткәрелә.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылыту чорына әзерләү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- торак-коммуналь хуҗалык объектларын норматив техник файдалануны, биналарда билгеләнгән температура режимын саклауны, халыкның яшәү санитария-гигиена шартларын үтәүне;
- торак-коммуналь хуҗалык объектларының максималь ышанычлылыгын һәм экономияле булуын;
- торак фонды һәм социаль өлкә биналарының, коммуналь корылмалар җиһазларының, инженер-техник тәэмин итү

системаларының һәм төзелеш конструкцияләре хезмәтенең норматив сроклары үтәлүен;
- матди-техник чараларны һәм ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылыту чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү эшләре түбәндәгеләр белән ирешелә:
- вазифаи затларның федераль һәм өлкә законнарын, муниципаль норматив хокукый актларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен, җитәкчелек һәм инструкцияләр таләпләрен үтәүләрен;
- төзелеш, капиталь һәм агымдагы ремонт планнары, шулай ук торак-коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү буенча проект-смета документларын эшләүне һәм үтәүне;
- техник торышны, план-кисәтү тикшерүләрнең барлык төрләрен үткәрүне даими контрольдә тотуны, шулай ук аварияләр һәм төзексезлекләр килеп чыгу сәбәпләрен җентекләп анализлау һәм ремонт-торгызу эшләренең тиешле күләмен билгеләүне;
- билгеләнгән вакытка һәм таләп ителә торган сыйфат, бурычларны нәтиҗәле кую системасы белән ремонт-торгызу эшләренә йомгак ясау һәм төгәл оештыруны;
- торак-коммуналь хуҗалык оешмаларын эксплуатацион һәм эксплуатацион-ремонт персоналы белән билгеләнгән бурычларны хәл итүне тәэмин итәрлек дәрәҗәдә комплектлауны;
- ремонт-торгызу эшләрен матди-техник тәэмин итүне, эксплуатация ихтыяҗларына фондның капиталь һәм агымдагы ремонтларына кирәкле максатлы финанслар бүлеп бирүне, матди ресурсларны рациональ файдалануны;
- җылыту чоры башланыр алдыннан оештыру-техник чаралар уздыруны, җиһазларны эшләүгә тикшерүне һәм сынау комплексының тулы күләмдә үтәлешен тәэмин итүне.

## 2. Җылыту чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия эше.

2.1. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәгеләрне оештыра:
- җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекнең җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

- торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль өлкә объектларының җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;
- торак фондының җылылык кабул итүгә әзерлеген тикшерүне, дежур сменалары һәм аттестацияләнгән персоналның әзерләнгән авария бригадалары белән комплектланганлыгын, аларны авария хәле очрагына МТР запасы, ягулык һәм химик реагентлар белән тәэмин ителгәнлеген.

Җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекләрнең җылылык челтәрләре һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның җылыту чорына әзерлеген бәяләү билгеләнгән тәртиптә Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган комиссия тарафыннан 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Комиссия эше җылылык бирү чорына әзерлек буенча тикшерү үткәрү графигы (1 нче таблица) нигезендә гамәлгә ашырыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:
-тикшерелергә тиешле объектлар;
-тикшерү үткәрү сроклары;
-тикшерү барышында тикшерелгән документлар.

Таблица №1

Җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү уздыру графигы

| № т/б | Тикшерелергә тиешле объектлар | Объектлар саны | Тикшерү үткәрү сроклары | Тикшерү барышында каралган документлар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык челтәрләре оешмалары | 2 | 3 кушымтага ярашлы | 4 кушымтага ярашлы |
| 2 | Социаль-мәдәни көнкүреш объектлары | 82 | | 5 кушымтага ярашлы |
| 3 | Торак фонды | 190 | | |

**Тикшергән вакытта комиссия тарафыннан җылылык чорына әзерлекне тикшерүне** үткәрү Программасының 4, 5 нче кушымталарында билгеләнгән

таләпләрнең үтәлеше тикшерелә (алга таба - Программа).

РФ Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы (алга таба - Кагыйдәләр) белән расланган җылылык челтәрләре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге техник регламентларда һәм башка норматив хокукый актларда Кагыйдәләр белән билгеләнгән тиешле мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү комиссия тарафыннан башкарыла.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә техник регламентларның яки башка норматив хокукый актларның Кагыйдәләр белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләре булмаган очракта, комиссияләр җылылык чорына әзерлек тәртибен җайга салучы тикшерелергә тиешле оешмаларның локаль актларын үтәүләрен тикшерә.

2.2. Тикшерү үткәрү максатларында, комиссия әзерлек буенча таләпләрнең үтәлешен раслый торган документларны карый, ә кирәк булганда - тикшерү объектларын карап тикшерә.

Тикшерү нәтиҗәләре җылылык чорына әзерлекне тикшерү акты (алга таба - акт) белән рәсмиләштерелә, ул тикшерү тәмамланганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча, әлеге Программага 1 нче кушымта нигезендә тәкъдим ителә торган үрнәк буенча төзелә.

Актта тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссиянең түбәндәге нәтиҗәләре бар:

- тикшерү объекты җылыту чорына әзер;

-тикшерү объекты, билгеләнгән срокта комиссия биргән әзерлек таләпләренә җитешсезлекләрне бетерү шарты белән, җылылык бирү чорына әзер булачак;

-тикшерү объекты җылыту чорына әзер түгел.

Комиссиядә әзерлек таләпләрен үтәүгә карата шелтәләр булган очракта, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, актка шелтәләр Исемлеге (алга таба - Исемлек) теркәлә.

Ягу чорына әзерлек паспорты (алга таба-паспорт) әлеге программага 2 нче кушымта нигезендә, һәр объект буенча актка кул кую датасыннан соң 15 көн эчендә, тикшерү объекты җылылык чорына әзер булса, шулай ук комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек таләпләренә карата шелтәләр Исемлектә билгеләнгән срокта юкка чыгарылган очракта, тәкъдим ителгән үрнәк буенча төзелә.

Әлеге Программаның 1 нче таблицасында билгеләнгән срокларда әзерлек таләпләрен үтәүгә (үтәлмәүгә) карата күрсәтелгән кисәтүләрдән арынылган очракта, комиссия кабат тикшерү уздыра, аның нәтиҗәләре буенча яңа акт төзелә.

Әлеге Программаның 1 нче таблицасында билгеләнгән көнгә кадәр тикшерү объектлары буенча әзерлек паспорты алмаган оешма җылылык чорына әзерлекне дәвам итәргә һәм актта күрсәтелгән таләпләрне үтәү (үтәлмәү) буенча күрсәтмәләрне юкка чыгарырга тиеш. Әзерлек таләпләрен үтәүгә (үтәлмәү) кисәтүләрне бетерү турында комиссия белдерүеннән соң кабат тикшерү гамәлгә ашырыла. Комиссиянең уңай бәяләмәсе вакытында җылылык бирү чорына әзерлек турында нәтиҗә белән кабат акт рәсмиләштерелә.

3. Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның Комиссия белән үзара хезмәттәшлеге тәртибе.

3.1. Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары 3 нче кушымтада күрсәтелгән әзерлек таләпләрен үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар.

Комиссия Программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслый торган документларны карый.

3.2.Җылылык энергиясен кулланучылар җылылык белән тәэмин итүче оешмага 4нче кушымтаның 2, 5, 8 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма җылылык куллану системаларын су белән юдырту һәм опрессовкалау вакытында катнаша һәм тикшерү объектларын карауны уздыра.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма кулланучыларның җылылык бирү чорына әзерлеген тикшерү актын рәсмиләштерә һәм аны Комиссия каравына җибәрә.

Комиссия Программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслый торган документларны карый.

№1 кушымта
«Җылылык белән тәэмин итү чорына
әзерлекне тикшерү үткәрү»
муниципаль программасына

Җылыту чорына әзерлекне тикшерү АКТы №________
20____/20___ еллар

шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе"_____"____________ 20__ ел

Җылыту сезонына әзерлекне тикшерү уздыру программасына ярашлы оештырылган комиссия

___________________________________________________________,
(комиссия төзелгән документ формасы һәм аның реквизитлары)
"____"_________________ 20__ расланган
ш.____________________________________________
_____________________________________________________________
_________________,
Җылылык белән тәэмин итү чорына әзерлекне тикшерү үткәрә торган орган җитәкчесенең (аның урынбасарының) ФИА)

белән "___"____________20__елдан "___"_____________ 20__елга кадәр 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы "Җылылык белән тәэмин итү турында"гы Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итү чорына әзерлек тикшерелде

__________________________________________________________________________________________________________________________________________________

(җылылык чорына әзерлек тикшерелгән җылылык белән тәэмин итүче оешма, җылылык челтәре оешмасы, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)

Түбәндәге объектларның җылыту чорына әзерлеге тикшерелде:

1._____________________________________________________;

(объектның исеме, мең кв. метрда мәйданы)

2._____________________________________________________;

3._____________________________________________________;

__________________________________________________________________________________

Җитәкченең/ кулланучы вәкиленең Ф. И. А., вазифасы, телефоны)

Җылыту чорына әзерлекне тикшерү барышында комиссия түбәндәгеләрне билгеләде:___________________________________________________________.

(җылыту чорына әзерлек/әзер булмау

Җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия нәтиҗәсе:_______________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________

Җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү актына кушымта _ / _ _ * ел

Комиссия рәисе: ___________________/______________

(имза, имзаның расшифровкасы)

Комиссия рәисе урынбасары ________________/_______________

(имза, имза расшифровкасы)

Комиссия әгъзалары: ___________________/______________

(имза, имза расшифровкасы)

___________________/______________

(имза, имза расшифровкасы)

___________________/______________
(имза, имза расшифровкасы)

Әзерлекне тикшерү акты белән таныштым, актның бер нөсхәсен алдым:
"___"___________20__ел_________________________________________
__________________
(җылылык чорына әзерлек тикшерелгән җылылык белән тәэмин итүче оешма, җылылык челтәрләре оешмасы җитәкчесенең, җылылык энергиясен кулланучының имзасы, расшифровкасы)

**Җылыту чорына әзерлек буенча таләпләрне үтәү яки үтәмәү буенча** кимчелекләр исемлеге
№ _ _ _ "_____"______________ 20__ ел

1.____________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________

Кимчелекне бетерү вакыты -______________________
(дата)

2.____________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________

Кимчелекне бетерү вакыты -______________________
(дата)

3.____________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________

Кимчелекне бетерү вакыты______________________
(дата)

Кушымта № 2
“Җылыту сезонына әзерлекне
тикшерү уздыру”
муниципаль программасына

**Җылыту чорына әзерлек ПАСПОРТы**
**20____/20____ еллар**

Бирелде_______________________________________________________________,
(җылыту чорына әзерлек тикшерелгән җылылык белән тәэмин итүче оешма, җылылык челтәре оешмасы, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)

Җылыту чорына әзерлекне тикшерү уздырылган түбәндәге объектлар мөнәсәбәтендә:
1.________________________;
2.________________________;
3.________________________;

Җылыту чорына паспорт тапшыруга нигез:
Җылыту чорына әзерлекне тикшерү акты ___________ N_________.

_______________________/_________________________
(җылыту чорына әзерлекне тикшерүне уздыру буенча комиссиянең имзасы, имза расшифровкасы)

Кушымта № 3
«Җылыту чорына әзерлекне
тикшерү уздыру” муниципаль
программасына

**Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык челтәре оешмаларының һәм җылылык энергиясен кулланучы оешмаларның 2019-2020 еллардагы көзге-кышкы чорга әзерлеген тикшерү графигы**

| № т/б | Административ район | Предприятиенең исеме | Инспекторның Ф.И.А. | Тикшерү датасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ютазы | «Теплосервис» МУП | Липатов А.И.<br>Хәбибуллина А.Н<br>Пайменддев И.Ю.<br>Нуруллина Р.М.<br>.<br>. | 05.08.2019 |
| 3 | | Җылылык энергиясен кулланучылар | | 13.06.2019 - 30.08.2019 |

Кушымта № 4
“Җылыту сезонына әзерлекне
тикшерү уздыру”
муниципаль программасына

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары

өчен җылылык чорына әзерлек буенча таләпләр

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының җылыту чорына әзерлеген бәяләү максатларында комиссия тарафыннан әлеге оешмаларда түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш:

1) җылылык белән тәэмин итү турында Законда билгеләнгән тәртиптә җылылык белән тәэмин итү системасы белән идарә итү турында килешү булу;

2) җылылык йөкләнеше графигын үтәүгә, температура графигын саклауга әзерлек;

3) техник регламентларда билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү ышанычлылыгы критерийларын үтәү;

4) эксплуатация, диспетчерлык һәм авария хезмәтләре эшчәнлеге, аерым алганда:

күрсәтелгән хезмәтләрне персонал белән тәэмин ителеше;

- персоналның шәхси һәм коллектив саклану чаралары, махсус киемнәр, эш кораллары белән тәэмин ителеше,

- норматив-техник һәм оператив документлар, инструкцияләр, схемалар,

- беренчел янгын сүндерү чаралары;

5) үзләренеке булган җылылык челтәрләрен төзәтүне уздыру;

6) җылылык энергиясен куллану режимнарын контрольдә тотуны оештыру;

7) җылылык белән тәэмин иткечнең (теплоноситель) сыйфатын тәэмин итү;

8) сатып алына һәм сатыла торган җылылык энергиясенең коммерция учетын оештыру;

9) Җылылык белән тәэмин итү турында закон нигезендә үз карамакларындагы җылылык челтәрләре төзелеше сыйфатын тикшерүне тәэмин итү, шул исәптән төзелештә кулланыла торган эшләргә гарантияләр һәм материаллар бирү;

10) җылылык белән тәэмин итү объектларының авариясез эшен һәм җылылык энергиясен кулланучыларны ышанычлы рәвештә җылылык белән тәэмин итүне, ә аерым алганда:

- аны эксплуатацияләү вакытын озайту буенча тиешле оештыру-техник чараларын үткәрмичә, ресурстан тыш җылылык энергетикасы җиһазларын эксплуатацияләү фактларының булмавын;

- торак йортларны җылылык белән тәэмин итү буенча авария хәлендәге кагыйдә бозулардан арыну вакыты исәбе булуын;

- җылылык, электр, су белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлендәге шартларны бетерү тәртибе булуын;

- җылылык челтәрләренә гидравлик һәм җылылык сынаулары үткәрүне;

- җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы җиһазларны кирәкле техник тикшерү һәм диагностика үткәрү кертелгән җылылык чорына әзерлек буенча расланган планны үтәүне;

җылылык челтәрләрен һәм җылылык энергиясе чыганакларын ремонтлау буенча план графигын үтәүне;

11) җылылык энергиясен кулланучылар, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары арасында эксплуатация җаваплылыгын чикләүне билгеләүче документлар булуны.

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларына карата кимчелекләрне бетерү срокларын күрсәтеп, Исемлек белән акт төзелә торган шартларга әлеге Кушымтаның 1, 7, 9 һәм 10 пунктчаларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.

Кушымта №5
«Җылыту чорына
әзерлекне тикшерү уздыру”
муниципаль программасына

Җылылык энергиясен кулланучылар өчен
җылыту чорына әзерлек буенча таләпләр

Җылылык энергиясен кулланучыларның җылыту чорына әзерлеген бәяләү максатларында вәкаләтле орган тарафыннан тикшерелергә тиеш:

1) җылылык белән тәэмин итү челтәрләрен юдыру уздыру;

2) ремонт эшләре планын үтәү һәм аларны үтәү сыйфаты;

3) җылылык энергиясен кулланучыныкы булган җылылык челтәрләренең торышы;

4) биналарның җылытылганлык (утепление) торышы (чарлаклар, баскыч клеткалары, подваллар, ишекләр);

5) торбаүткәргечләр, арматура һәм җылылык изоляциясе торышы;

6) исәпләү приборлары булу һәм аларның эшкә сәләтлелеге;

7) хезмәт күрсәтүче персонал өчен принципиаль схемалар һәм инструкцияләр булуы һәм аларның дөреслеккә туры килүе;

8) үзләренең һәм (яки) җәлеп ителгән ремонт бригадаларының булуы һәм аларның җылылык кулланучы объектларны тиешенчә эксплуатацияләү өчен матди-техник ресурслар белән тәэмин ителгәнлеге;

9) РФ Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы "Җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында"гы №103 боерыгының 3 кушымтасында китерелгән критерийлары нигезендә, климат шартларын исәпкә алып, җылылык энергиясе кулланучыларын җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы.

Җылылык энергиясен кулланучыларга карата кисәтүләрне бетерү срокларын күрсәтелгән Исемлек белән акт төзелә торган шартларга әлеге Кушымтаның 6, 9 пунктчаларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.